# 9 нчы сыйныф

“Казан – борынгы шәһәр” тексты буенча БРТга әзерләү

Казан – борынгы шәһәрләрнең берсе. Ул – Татарстан Республикасының башкаласы. Хәзер Каазанның мәйданы 425 квадрат километрдан артык. Казанда миллионнан артык кеше яши.

Казан – зур промышленность шәһәре. Анда машина җитештерү промышленносте, җиңел промышленность, азык-төлек промышленносте үскән.

Казанга су юлы белән дә, тимер юл белән дә, самолет белән дә барып була.

Күптән түгел Казанга экскурсиягә бардык. Казан – искиткеч матур шәһәр. Бигрәк тә безгә Казан Кремле ошады. Анда Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы урнашкан. Кремль янындагы мәйданда герой-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куелган.

Казанда Татар дәүләт академия театры бар. Ул Галиәсгар Камал исемен йөртә. Театр Кабан күле буендагы бик матур бинада урнашкан. Театрда драмалар, комедияләр куела. Иң атаклы спектакльләрнең берсе – “Беренче театр”. Пьесаның авторы – Галиәсгар Камал. Театрда Равил Шәрәфиев, Ринат Тәҗетдинов, Нәҗибә Ихсанова, Алсу Гайнуллина, Люция Хәмитова һәм башка күренекле артистлар эшли.

**“Казан” тексты буенча эш. Туры киләме, килмиме, шуны билгеләү.**

1. Туры килә. 2. Туры килми

1. Казан – Башкортстан Республикасының башкаласы.
2. Казанда миллионнан ким кеше яши.
3. Казан – зур промышленность шәһәре.
4. Казанга төрле юл белән барып була.
5. Безгә бигрәк Г.Камал театры ошады.
6. Кремльдә Нурулла мәчете бар.
7. Кремль янындагы мәйданда М.Җәлил һәйкәле бар.
8. Г.Камал театры Казансу елгасы буенда урнашкан.
9. Иң атаклы спектакльләрнең берсе – “Галиябану”.
10. “Беренче театр”ның авторы – Г.Камал.

# Һәр абзацка тиешле саннарны сайлап язарга

**А**. 1 нче абзац

**Ә**. 2 нче абзац

**Б**. 3 нче абзац

**В**. 4 нче абзац

**Г**. 5 нче абзац

1. Татар дәүләт академия театры бинасы

# Тиешле кушымчалар өстәп язарга

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Ул – Татарстан Республикасының ____ . | башкала |
| 2 | Казанда _____ артык кеше яши. | миллион |
| 3 | Күптән түгел Казанга _____ бардык. | экскурсия |
| 4 | Бигрәк тә безгә Казан Кремле _____ . | ошарга |
| 5 | Кремль янындагы ____ герой-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куелган. | мәйдан |
| 6 | Театр Кабан күле буендагы бик матур бинада _____ . | урнашырга |
| 7 | Пьесаның ____ – Галиәсгар Камал. | автор |

# Җаваплар

1. 2
2. 2
3. 1
4. 1
5. 2
6. 2
7. 1
8. 2
9. 2
10. 1

А. 3
Ә. 5
Б. 6
В. 2